КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 22 июль г.Казань № 540

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасының кайбер дәүләт учреждениеләре дәүләт эшләренә, хезмәт күрсәтүләренә һәм дәүләт хезмәтләре күләмнәренә норматив чыгымнарны раслау турында» 2024 ел, 18 сентябрь, 812 нче карары белән расланган 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасының кайбер дәүләт учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган дәүләт эшләренә норматив чыгымнарга үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасының кайбер дәүләт учреждениеләре дәүләт эшләренә, хезмәт күрсәтүләренә һәм дәүләт хезмәтләре күләмнәренә норматив чыгымнарны раслау турында» 2024 ел, 18 сентябрь, 812 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 12 май, 309 нчы, 2025 ел, 24 май, 350 нче, 2025 ел, 29 май, 371 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасының кайбер дәүләт учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган дәүләт эшләренә норматив чыгымнарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктның «вазыйфаи затларга, дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм дәүләт, муниципаль учреждениеләргә транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру һәм гамәлгә ашыру» юлының 4 нче графасында «370 519 446,58» саннарын «374 045 746,58» саннарына алмаштырырга;

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «2.4. | «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе | юл эшчәнлеген гамәлгә ашырганда гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чараларын үткәрү | 895 844 532,0 | 899 669 332,0 | 903 685 432,0 |
| | | транспорт чараларының үлчәү һәм габарит параметрларын үлчәү | 277 874 782,0 | 277 874 782,0 | 277 874 782,0 |
| | | яшьләр сәясәте өлкәсендә яшьләрне инновацион, эшмәкәрлек, ихтыяри ярдәм эшчәнлегенә җәлеп итүгә, шулай ук яшьләрнең гражданлык активлыгын үстерүгә һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар оештыру | 49 079 076,0 | 49 079 076,0 | 49 079 076,0 |
| | | транспорт чараларын күчерүне һәм саклауны оештыру, шулай ук махсуслаштырылган транспорт куеп тору урыннарын эксплуатацияләү (тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган транспорт куеп тору урыннарына күчерү) | 136 678 415,0 | 136 678 415,0 | 136 678 415,0 |
| | | транспорт чараларын күчерүне һәм саклауны оештыру, шулай ук махсуслаштырылган транспорт куеп тору урыннарын эксплуатацияләү (махсуслаштырылган транспорт куеп тору урыннарында тоткарланган транспорт чараларын саклау һәм исәпкә алу) | 137 106 244,0 | 137 106 244,0 | 137 106 244,0 |
| | | оешма эшчәнлеген административ тәэмин итү (анализ үткәрү) | 51 775 400,0 | 51 775 400,0 | 51 775 400,0 |
| | | оешма эшчәнлеген административ тәэмин итү (экспертиза үткәрү) | 38 983 000,0 | 38 983 000,0 | 38 983 000,0 |
| | | оешма эшчәнлеген административ тәэмин итү (сатып алуларны оештыру) | 15 669 500,0 | 15 669 500,0 | 15 669 500,0 |
| | | мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасының мәгълүмат систе- | 83 065 900,0 | 83 065 900,0 | 83 065 900,0 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | маларын һәм компонентларын булдыру һәм үстерү | | | |
| | | гамәли фәнни тикшеренүләр үткәрү | 18 225 000,0 | 18 225 000,0 | 18 225 000,0 |
| | | мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасы компонентларын техник тәэмин итү һәм эксплуатацияләү, эксплуатациядән чыгару | 87 914 100,0 | 87 914 100,0 | 87 914 100,0 |
| | | мәгълүмат ресурсларын һәм мәгълүмат базаларын алып бару | 29 389 800,0 | 29 389 800,0 | 29 389 800,0»; |

13.1 пунктның «оешма эшчәнлеген административ тәэмин итү (мониторинг уздыру)» юлының 4 графасында «84 186 051,28» саннарын «85 373 751,28» саннарына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин